**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ**
**НИЖНЕКАРМАЛКИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423102, СЕЛО НИЖНЯЯ КАРМАЛКА,
УЛ.ЛЕНИНА, Д.44

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ТУБӘН КАРАМАЛКА АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

423102, ТУБӘН КАРМАЛКА АВЫЛЫ,
ЛЕНИНА УРАМЫ,44 ЙОРТ

Тел.: (84396)2-39-47 ФАКС: (84396) 2-39-47

Email: Nkar.Cmn2@tatar.ru

№140 24 октябрь 2019 ел

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Тубән Карамалка авыл җирлеге Советы карары

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Тубән Карамалка авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге Уставына**
**үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасының «Чирмешән муниципаль районының Тубән Карамалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Тубән Карамалка авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Тубән Карамалка авыл җирлеге Советының 56 номерлы карары белән (Түбән Кармалка авыл җирлеге Советының 2014 елның 7 апрелендәге 66 номерлы, 2015 елның 8 маендагы 97 номерлы , 2016 елның 23 гыйнварендәге 17 номерлы, 2016 елның 15 декабрендәге 39 номерлы, 2017 елның 29 маендагы 48 номерлы, 2017 елның 16 декабрендәге 67 номерлы, 2018 елның 19 июлендәге 85 номерлы, 2019 елның 15 апрелендәге 115 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) 2013 елның 15 июлендә кабул ителгән Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы Тубән Карамалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 22 статьяга киләсе пунктны өстәргә: «3.1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясында каралган гражданнар җыены анда торак пункт яки җирлектә сайлау хокукына ия

яшәүчеләрнең яртысыннан артыграгы катнашса вәкаләтле дип исәпләнә. Торак пунктта әлеге торак пунктта сайлау хокукына ия булган яртысыннан артыграк яшәүчеләрнең бер үк вакытта бергә булу мөмкинлеге булмаса, гражданнар җыены әлеге Устав нигезендә этаплап, гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул ителгән көннән алып бер айдан да артмаган вакыт эчендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Карамалка авыл җирлеге торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә белән расланган тәртиптә үткәрелә. Шул ук вакытта элек гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә киләсе этапларда катнашмый. Гражданнар җыены карары кабул ителгән дип санала, әгәр җыенда катнашучыларның яртысыннан артыгы аның өчен тавыш биргән булса».

1.2. 49 статьяның 2 өлешендәге 19 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыра».

1.3. 80 статьяны яңа редакциядә бәян итәргә: «1. Үзара салым акчалары дигәндә, гражданнарның җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен бер тапкыр башкарыла торган түләүләре аңлашыла. Гражданнарның үзара салымы күләме, авыл җирлегендә (җирлек составына керүче торак пунктта) яшәүчеләрнең гомуми саныннан 30 проценттан артмаган түләү күләме киметелергә мөмкин булган аерым категория гражданнардан тыш, барлык авыл (җирлек составына керүче торак пункт) халкы өчен дә абсолют күләмдә тигез билгеләнә.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән гражданнар тарафыннан бер тапкыр бирелә торган түләүләрне кертү һәм куллану мәсьәләләре җирле референдумда, ә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясындагы 1 өлешенең 4.1 пунктында каралган очракларда гражданнар җыенында хәл ителә.

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Дәүләт теркәвеннән соң әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы «Түбән Карамалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 87 статьясындагы 2 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Түбән Карамалка авыл җирлеге
Башлыгы Урынбасары, Совет Рәисе урынбасары Е.Н.Денисова